РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**И С П О Л К О М**
**Кирельского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**И С П О Л К О М**
**Кирельского сельского поселения**

Улица Гагарина , дом 1, Камско-Устьинский район, 422827, телефон 8(277)- 3-67-45. ИНН-1622004725 ОГРН-1061672020453 ОКАТО-92230830000 ЛБ-222160029 р/с 40204810100000420010 ГРКЦ НБ РТ г.Казань БИК-049205001 КПП-162201001

Гагарина Ур, Кама-Тамагы, районы, 422827,телефон 8 (277)-367-45. ИНН-1622004725 КПП-162201001 ОГРН-1061672020453 ОКАТО-92230830000 ЛБ-222160029 р/с-40204810100000420010 ГРКЦ НБ РТ г. Казань БИК 049205001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 20 сентябре № 18

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге Башкарма комитеты

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

**- Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
**- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**
**- Күмү урыннарын карап тоту;**

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

Кирельский авылы, Гагарин урамы, 1 йорт (административ бина);
Кирельское авылы, Гагарин урамы, 14 йорт («Раифа " кибете»)
Кирельский авылы, Түбән урамы, 6 йорт (китапханә);
Ишем авылы, Үзәк урамы, 10 йорт (авыл клубы);
Мордва Каратай авылы, Үзәк урам, 7 йорт (КФҮ бинасы), шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Кирельский авылы җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** Ф. Я. Зиннатуллин